| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 5 декабрь № 892

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» 2007 ел, 2 август, 366 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» 2007 ел, 2 август, 366 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 8 октябрь, 543 нче; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 14 май, 321 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2013 ел, 29 октябрь, 806 нчы; 2015 ел, 15 гыйнвар, 7 нче; 2015 ел, 13 апрель, 250 нче; 2016 ел, 19 август, 576 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Гражданнарга социаль ипотека буенча торак урыннар бирү тәртибендә:

1.10 нчы пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.10. Җирле үзидарә органнарында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә куелган гражданнар торак урынны сайлау гамәлгә ашырыла торган календарь елда, фатир сайлау беркетмәсен имзалаганга кадәр, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәменә хокукын раслау максатларында, әлеге исәпкә куелган урын буенча яңадан теркәлергә тиеш.»;

2.10 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Конкурс йомгаклары турында хисапны раслаган көннән соң 10 эш көне эчендә гражданнар беренчел фатир сайлау беркетмәсен имзалый.

Гражданнар социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәменә хокукын раслау һәм торак йортны эксплуатациягә кертү шарты белән Торак фондының Попечительләр советы раслый торган форма буенча фатир сайлау беркетмәсе рәсмиләштерелә. Фатир сайлау беркетмәсе социаль ипотека шартнамәсенең аерылгысыз өлеше булып тора һәм конкурста җиңүченең сайлаган фатирына күчену һәм аннан файдалану хокукын таныклый.

Фатир сайлау беркетмәсе, сайлаган фатиры урнашкан торак йорт эксплуатациягә кертелгән көннән соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, граждан тарафыннан имзалана.

Граждан әлеге пунктның өченче абзацында каралган вакыт эчендә фатир сайлау беркетмәсен имзаламаган очракта, гражданның фатир сайлау буенча конкурс йомгаклары һәм беренчел фатир сайлау беркетмәсе гамәлдән чыгарыла.

Объектны эксплуатациягә кертү көне һәм сайлаган фатирга күченү мөмкинлеге турындагы мәгълүмат Торак фонды тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында объект эксплуатациягә кертелгән көннән соң 10 календарь көн эчендә урнаштырыла.»;

4.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«объектны эксплуатациягә кертү көне һәм сайлаган фатирга күченү мөмкинлеге;»;

әлеге карар белән расланган Социаль ипотека буенча торак сатып алу өчен гражданнар түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм вакытларын билгеләү тәртибендә:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гариза бирүче, фатир сайлау беркетмәсен рәсмиләштергән вакыттан башлап, торак урынның гомуми мәйданының түләнмәгән өлеше өчен наемга түли.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\892.docx